**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Карамалы авыл җирлеге Советы КАРАРЫ**

Карамалы авылы № 84 "07"апрель 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 июнь 98 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарның шәхси кабул итүен тәэмин итү нигезләмәсенә үзгәреш кертү турында (09.10. 2018 №110, 19.03.2019 № 129,13.08.2019 №140 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Карамалы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советының 2018 елның 21.06 98 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарның шәхси кабул итүен тәэмин итү нигезләмәсенә (09.10. 2018 № 110, 19.03.2019 № 129,13.08.2019 №140 карарлар редакциясендә) «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда веб-адрес буенча: http://pravo. tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http//aznakayevo. tatar.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис А.Р.Ногманов